**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 19 сентябрь № 659

г. Казань

Территориаль аерымланган «ИнноКам» инновация-җитештерү үзәген төзү концепциясен тормышка ашыру буенча чаралар планын («юл картасын») раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 июнендәге б-1257 нче боерыгы белән расланган Территориаль аерымланган «ИнноКам» инновация-җитештерү үзәген төзү концепциясен тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышы йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Территориаль аерымланган «ИнноКам» инновация-җитештерү үзәген төзү концепциясен тормышка ашыру буенча чаралар планын («юл картасын») (алга таба – «юл картасы») расларга.

2. Татарстан Республикасы министрлыкларына һәм ведомстволарына, мәнфәгатьле оешмалар белән берлектә, «юл картасы» чараларын тормышка ашыруны һәм квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 15 енә кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына «юл картасы» чараларын тормышка ашыру барышы турында мәгълүмат кертүне тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 25 енә кадәр, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «юл картасы» чараларын тормышка ашыру барышы турында җыелма хисап кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков